БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
16 декабрь 2020 ел

**КАРАР**
№ 28

**«2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2019 елның 17 декабрендәге 219 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. «2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2019 елның 17 декабрендәге 219 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2020 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 979114,0 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 1003031,3 мең сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 23917,3 мең сум итеп».

1.2. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны түбәндәгечә исәпкә алырга:

- әлеге карарның 18 нче кушымтасы нигезендә 2020 елда 684907,7 мең сум итеп;

- әлеге карарның 19 нчы кушымтасы нигезендә 2021 елда 575314,42 мең сум һәм 2022 елда 580989,34 мең сум итеп.»

1.3. Карарның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2020 елга 15103,9 мең сум, 2021 елга 15200,00 мең сум, 2022 елга 15900,00 мең сум итеп расларга һәм аларны тиешенчә 2020, 2021 һәм 2022 елларда Балтач муниципаль районының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.».

1.4. Әлеге карарның 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 6 нчы, 7 нче кушымталары нигезендә «2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2019 елның 17 декабрендәге 219 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарының 1 нче, 3 нче, 6 нчы, 8 нче, 10 нчы, 18 нче, 20 нче кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябереннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин